# Исламча яшәү рәвеше

Егерменче гасыр башында Тукай һәм Исхакыйлар “Милләт бетәме, әллә исән каламы?” - дип өзгәләнсәләр, егерме беренче йөз башында да татар халкы каршында шул ук сорау тора – милләт бетәме, әллә исән каламы? Югыйсә, Тукай һәм Исхакыйлар көткән тәррәкыять тә килде, халык хәзер укымышлы, телләр белә, дөньядан артта калмый, ә хәле барыбер шәптән түгел. Узган гасыр башында милләткә телсезлек һәм динсезлек проблемасы янамаган, бүген исә бу хәл иң куркыныч афәткә әйләнеп бара. Табипларның әйтүе буенча, Татарстанда һәр дүрт кешенең берсе эчкече яки наркоман, бу мәсьәләдә дәүләт ашыгыч чаралар күрмәсә, тагы егерме елдан халыкның яртысы юкка чыгачак. Бу хәл турыдан-туры татарларга да карый, чөнки эчкечелек, наркомания, фахишәлек, җинаятьчелек, хәрам кебек ахырзаман афәтләре татар дөньясына да үтеп керде һәм китмәскә дип килде. Төрле программалар язып, корылтайлар уздырып кына бу хәлне туктатып булмаячак, милләтнең, һәр татарның бу фаҗигане тирәннән аңлавы һәм исән калу өчен көрәшә башлавы кирәк.

Татарның меэнәрчә елларга сузылган бөек тарихын һәм бүгенге хәлен өйрәнүче кеше буларак шуны әйтә алам – милләтебезнең соңгы йөз ел эчендә булган рухи югалтулары барысы да динсезлек нәтиҗәсе ул. Татарныћ күпләп диннән чыгуы егерменче йөз башында ук башланып, гасыр буе дәвам итте, совет режимы исә моңа тагы да зур этәреч бирде, иманда калырга теләүчеләрне үзе юк итте. СССР – Аллаһтан рәсми рәвештә баш тарткан бердәнбер ил ул, һәм безнең бәхетсез милләтебез дә шул алласыз идеологиянең корбаны булды. Бу – барыбызга да таныш тарих, һәм аның аянычлы нәтиҗәсе дә билгеле.

Инде егерменче гасыр азагында, дингә килергә бераз ирек ачылгач та, диннән бизгән халкыбыз исламга әйләнеп кайтырга ашыкмады, ирек һәм хөрриятне ул үзенчә яшәү, дип кабул итте, һәм моның да аянычлы нәтиҗәсен инде барыбыз да күрәбез. Татар халкы Аллаһы Тәгаләне әйләнеп үтеп, бәхетле булырга теләде, нәтиҗәдә әхлаксызлык сазлыгына кереп батты, гаделсезлектән газаплана башлады, юллар чатында адашып калды. Аз-маз дингә килгәннәр дә исламны яшәү рәвешенә әйләндерә алмады, ул тагы ритуалга, йолага гына әйләнеп кала башлады. Чөнки ислам дине җәмгыятькә, милләт тормышына, мәктәп һәм югары уку йортларына, матбугат чараларына, радио һәм телевидениега үтеп керә алмады, ул мәчетләрдән һәм аерым мөселманнарның өйләреннән ары китмәде. Ислам дине татарның яшәү рәвешенә әйләнмәде...

Исламча яшәү рәвеше... Ул нәрсә дигәнне аңлата соң? Ул мљселманнарга гына кагыламы, әллә инде бар халыкка да карыймы? Дингә килү ул әле исламча яшәү дигәнне аңлатамы, дин тотмаган кешеләргә бу таләпләр карыймы? Мөмкинлекләр булып та, нигә милләтебез исламның ишек төбендә генә тора, дин дөньясына үтәргә аңа нәрсә комачаулый? Әгәр милләт Аллаһтан һәм Аның җәзасыннан курыкса, Ул кушканча яшәр иде бит! Нигә татар халкы динне һаман җиңелгә саный, нигә мөмкинлекләр була торып та, исламча яши башламый? Хәзер шул сорауларга да җавап биреп китәргә тырышырбыз.

Әйе, намаз укый башлау, мөселманча киенү ул исламча яшәүнең башы булырга мәмкин, әмма бу әле тулысынча исламча яшәү рәвешенә күчүне аңлатмый. Чөнки дин намаздан башланса да, аның белән генә бетми, ул кешенең яшәү рәвешенә әйләнергә

тиеш. Үзен мөселман өммәте дип атаган татар халкының тормышында да ислам дине яшәү рәвеше булып торырга тиеш. Ә исламча яшәү – ул гаделлек, дигән сүз, ә бүгенге көндә татар тормышында гаделлек юк. Татар тормышы бер-берeңне алдау, бер-берeңне талау, икейөзлелек, кеше хакына керү, ришвәтчелек, хәрам белән тулы. Бу хәл иң зур түрәләрдән башланып, авыл агаена хәтле төшеп җиткән. Бөтен төшемле урыннар, бай җирләр, дан-дәрәҗәләр сатыла, эш урыны сатыла, уку урыны сатыла, квартиралар сатыла, иң куркынычы, кеше үзе дә сатыла... Бүген татар дөньясында кеше иманга һәм талантка карап билгеләнми, ә урынына һәм байлыгына карап бәяләнә. Ә ул урын сатып алынган, ә байлык халыкны талап җыелган була. Һәм шундый кешеләр дөнья белән идарә итәләр, әмир булып әмерләр бирә башлыйлар. Пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәламнең бер хәдисе бар, ул: “Әмерләр әмир булырга тиеш булмаган кешеләрдән бирелә башласа, соңгы сәгатьне көт”, - дигзн. Татарның соңгы сәгате дә хаксыз, имансыз кешеләрне үз башына утыртудан башланыр, мөгаен... Бу сүзне, әлбәттә, ирләр әйтергә тиеш иде, әмма алар әйтмәгәч, без күтәрергә мәҗбүр булдык, чөнки бу гаделсезлекне тудыручылар, нигездә, татар ирләре үзләре.

Исламча яшәү – ул әхлак, дигән сүз, ә бүгенге көндә татар тормышында әхлак юк. Эчкечелек, зина, наркомания, шәрәлек, азгынлык татар дөньясында гадәти хәлгә әйләнеп бара, моның буенча беркем чаң какмый, күпләр бу хәл белән килешеп, әхлаксызлыкны яшәү рәвешенә әйләндерделәр. Гаделсезлекнең башында ир-ат торса, әхлаксызның башында татар хатын-кызлар үзләре тора. Моның шулай икәнлегенә ышанасыгыз килсә, татар телевидениесенә һәм сәхнәләргә генә күз салыгыз – иң нык чишенгәннәре татар хатын-кызлары булыр. Аларга дин әһелләре дә, каләм әһелләре дә бер сүз әйтми, димәк, шушы азгынлык, тән зинасы, күз зинасы белән җәмәгатьчелек килешә, дигән сүз. “Матурлык”, дигән ялган астында бүгенге көндә безгә татар сәхнәсеннән шәрә азгынлык тәкъдим итәләр. Әмма Аллаһы Тәгаләнең :”Һәр өммәткә үзләренең кылган гамәлләрен зиннәтле итеп күрсәттек. Инде аларны азгынлыкларында калдырабыз”, - дигән аятьләрен онытмыйк!

Татар хатын-кызларыныћ никахсыз, сөяркә булып торулары, зинадан бала табулары да бернинди шәригать кысаларына сыймый, әмма бу да татар тормышында гадәти хәлгә әйләнеп бара. Бу урында тагы пәйгамбәребез Мөхәммәт саллалаһу галәйһиссәламнең бер хздисен мисалга китерәм, ул: “Бер кавемдә начарлыктан тыючылар калмаса, Аллаһудан ярдәм киселер!” – дип әйтеп калдырган. Әгәр милләтне шушы азгынлыктан тыючылар булмый икән, әгәр халык шушы бозыклыклар белән килешә икән, безгә Аллаһның ярдәме бетәчәк бит! Һәм ул ярдәм әкеренләп бетеп килә бит инде, җәмәгать, бүгенге тормышыбыз шуның нәтиҗәсе бит!

Исламча яшәү рәвеше ул – бер-береңә шәфәгатьлелек, милләтәшеңә, дин кардәшеңә эчкерсез ярдәм итү, аны авыр хәлдә калдырмау. Һәм бу яхшылыкны бәндә күрсен өчен дип түгел, Аллаһ ризалыгы өчен эшләү. Кызганычка каршы, милләт тормышында бу сыйфат әкренләп юкка чыгып бара, кеше рәхимсезләнде, катыланды, саранланды, явызланды. Ни кызганыч, шушы начар сыйфатлар хатын-кызлар арасына да үтеп керде, татар хатын-кызларының күпчелеге зәһәрлектә, ертлачлыкта, этлектә бүген күпләрне сыртына сала һәм шуның белән чиксез горурлана, имеш, дөньяның артына тибеп яши! Әмма дөнья бер көнне үзе аның артына тибәчәк һәм бу явыз хаты-кыз җәһәннәмнең түрендә булачак. Аллаһтан курыкмау хатын-кызны бу дөньяда оятсыз итсә, теге дөньяда бәхетсез итәчәк... Бу хакта Коръәндә бик ачык кисәтелә бит:

“Алар хак динне җиңелгә һәм уенга санадылар һәм аларны дөнья байлыгы алдады, бүген Без дә аларны җәһәннәмгә салып онытырбыз, бу көннәренә юлыгачакларын онытканнары һәм аятьләребезне инкарь иткәннәре өчен”, диелә “Әгъраф” сүрәсенең 51нче аятендә.

Исламча яшәү рәвеше ул – милләтең һәм динең өчен гайрәт белән иҗтиһат итү, гамәл кылу, дигән сүз. Кызганычка каршы, бүген халык динем өчен түгел, көнем өчен, дип яши, диннән ерак тора, милләт, җәмәгать эшләрендә катнашмый. Халыкның битарафлыгыннан һәм пассивлыгыннан исә алдакчы сәясәтчеләр һәм оятсыз түрәләр, угры байлар файдалана, нәтиҗәдә, ялкау һәм надан татарларны тагы төп башына утыртып калдыралар... Ә җәмәгать булып яшәгән, шәригать кануннарын белгән кеше үзен алдарга ирек бирмәячәк, чөнки ул бар нәрсәне дин күзлегеннән чыгып, Аллаһ кушкан тәртип белән башкарачак.

Исламча яшәү рәвеше ул – гыйлемгә омтылу, үз тарихыңны яхшы белү, халкыңны бәйсез һәм бәхетле итәргә тырышу, дигән сүз. Әгәр татар халкы чыннан да үзен мөселман өммәте дип саный икән, ул кяферләрнең исламга һәм милләтебезгә каршы законнары буенча яшәргә тиеш түгел, ә бәлки үз мөстәкыйль дәүләтен торгызырга омтылырга тиеш. Бөек дин галиме, милләттәшебез Риза Фәхретдинов та: “Бер карышы булса да мөселманнар яшәгән җирнең мөстәкыйльлеге өчен тырышырга кирәк”, - дип әйтеп калдырган бит! Татар халкы заманында үзенең зур дәүләтләр тоткан мәгърур халык булганлыгын онытып бара, иреккә омтылмый, коллыгы белән килешеп, үзен империягә корбан итә.

Татар шуны яхшы аңларга тиеш – чит милләт һәм чит дин тәэсирендә калган халык озак үзе булып яши алмый, көннәрдән бер көнне барыбер шул милләтнең телен һәм динен алырга мәҗбүр була. Бу – бөтен дөньяда шулай, Россиядә исә бу процесс бигрәк тә тиз һәм аяусыз бара. Без бу ассимилияциягә, чит кавемгә әйләнүгә каршы бары тик үзебезнең бөек динебезне һәм мәдәниятебезне генә каршы куя алабыз. Әмма мәдәният тә озак түзмәячәк, чөнки телсез мәдәният була алмый, ә тел бетүгә таба бара. Димәк, әгәр татар милләт буларак исән калырга тели икән, ул ислам дине кушканча гайрәт белән үзенең бәйсез дәүләтен булдыру өчен көрәшергә тиеш, ислам әхлаклы, милли, гадел җәмгыять төзәргә омтылырга тиеш. Югыйсә безнең, кытай һәм урыс тегермәне арасында кысылып калып, ком бөртеге кебек тарих мәйданыннан юкка чыгуыбыз бар.

Шуңа күрә, бүгенге көндә халыкка ислам динен аңлату, ислам динен тарату ул дин әһелләренә генә эше түгел, ә барыбызның да изге бурычы. Татар галимнәре һәм язучылары, матбугат әһелләре һәм мәдәният хезмәткәрләре, татар укытучылары һәм милли сәясәтчеләр, зыялылар һәм җитәкчеләр барысы да милләтебезне динсезлек һәм әхлаксызлык сазлыгыннан өстерәп чыгаруда ярдәм итәргә тиешләр. Әмма моның өчен бу кешеләр башта үзләре исламча яшәү рәвешенә күчәргә, аннан халыкны да шушы юлга өндзргә тиешләр. Милләт буларак исән калырга уйлыйбыз икән, безнең башка юлыбыз юк, шушы юлга басабыз икән, безгә Аллаһы Тәгалә дәүләтен дә бирер, милләт буларак та саклап калыр, иншаллаһ!

**Фәүзия Бәйрәмова,**
***язучы, тарих фәннәре кандидаты,***
***Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы.***